| | |
|---|---|
| ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 ел 14 ноябрь** **№4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мостафин авылы гражданнары җыенын медпункт бинасында 2025 елның 29 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылында теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йортүче хезмәтләре өчен түләү);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә үлән чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, триммер өчен,

запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү), Чокырлы урамында шлагбаум кую өчен материаллар сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
4. Мостафин торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка кадәр керү юлын тозү - вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча түләү; зират территориясендә үлән чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, триммер өчен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу; коры агачларны кисү һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
5. Мостафино авылында җир асты суларын (чишмәләрне) территориясен төзекләндерү, беседка ясау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);»

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Нуртдинов